Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Аппак авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

31 январь 2022 ел № 1

Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы буенча Пенсия фонды бүлегенең Әлмәт районындагы Клиент хезмәте (бүлек хокукларында) 2022 елның 24 гыйнварындагы 54-34-09/206 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

Аппак авылы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6 964,68 сум күләмендә 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.

2.Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Аппак авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2021 елның 20 фералендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Аппак авылы, Мира урамы, 71йорт, Илтен-Бота авылы, Совет урамы,71 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Аппак авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.Н. Горбунова

Әлмәт муниципаль районы
Аппак авылы башкарма комитетының
2022 елның 31 январендәге 1 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 98,67 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3 998,90 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 621,26 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2 245,85 |
| Барлыгы | | 6 964,68 |

Аппак авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.Н. Горбунова

Әлмәт муниципаль районы
Аппак авылы башкарма комитетының
2022 елның 31 январендәге 1 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 98,67 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен төрү | 2 344,45 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 654,46 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 621,26 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2 245,84 |
| | Барлыгы | 6 964,68 |

Аппак авылы
башкарма комитеты җитәкчесе В.Н. Горбунова